**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

06.11.2020 № 327

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы финанс министры вазыйфасына билгеләп кую тәртибен раслау турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектының финанс органы җитәкчесенә куела торган квалификация таләпләрен раслау һәм Россия Федерациясе Финанс министрлыгының Россия Федерациясе субъекты финанс органы җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатларның туры килү-килмәвен тикшерүдә катнашуы турында» 2020 елның 11 сентябрендәге 1403 номерлы карары нигезендә:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы финанс министры вазыйфасына билгеләп кую тәртибен раслау турында» 2004 елның 14 декабрендәге 245 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъекты финанс органы җитәкчесенә һәм җирле администрациянең финанс органы җитәкчесенә куела торган квалификация таләпләре турында» 2004 елның 6 ноябрендәге 608 номерлы карары нигезендә» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектының финанс органы җитәкчесенә куела торган квалификация таләпләрен раслау һәм Россия Федерациясе Финанс министрлыгының Россия Федерациясе субъекты финанс органы җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатларның туры килү-килмәвен тикшерүдә катнашуы турында» 2020 елның 11 сентябрендәге 1403 номерлы карары нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы финанс министры вазыйфасына билгеләп кую тәртибен кушымта нигезендәге яңа редакциядә бәян итәргә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның « 06 » ноябрендәге
327 номерлы боерыгына
кушымта

**Татарстан Республикасы финанс министры вазыйфасына билгеләп кую тәртибе**

1. Татарстан Республикасы финанс министры вазыйфасына билгеләү Татарстан Республикасы Конституциясе һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә расланган тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан башкарыла.

2. Татарстан Республикасы финанс министры вазыйфасын биләүгә кандидат Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектының финанс органы җитәкчесенә куела торган квалификация таләпләрен раслау һәм Россия Федерациясе Финанс министрлыгының Россия Федерациясе субъекты финанс органы җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатларның туры килү-килмәвен тикшерүдә катнашуы турында» 2020 елның 11 сентябрендәге 1403 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәте карары) нигезендә расланган Россия Федерациясе субъектының финанс органы җитәкчесенә куела торган квалификация таләпләренә туры килергә тиеш.

3. Татарстан Республикасы финанс министры вазыйфасын биләүгә кандидатның квалификация таләпләренә туры килү-килмәвен тикшерүне, Россия Федерациясе Хөкүмәте карары таләпләрен үтәп, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты башкара.